# КАРАР

**23 ноябрь 2022 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, сход 23 ноябрь 2022 елда утте.:

"Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары,18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләр; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Совет урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- территорияне кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- Өркеш авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Подгорная урамы, Өркеш авылы (2 скважина)буенча артезиан скважиналарыннан файдалануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатория тикшеренүләре әзерләү чараларын тормышка ашыру . ;
- Өркеш авылы Подгорная урамында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өркеш авылында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;

« БЕЗ РИЗА» « БЕЗ КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 162 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 83 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 83 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләр; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә расларга булганнар:

- территорияне кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

- Өркеш авылында видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, сатып алу, урнаштыру, карап тоту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

- Өркеш авылында энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;

- кирәкле материал алу һәм булган чишмәне ремонтлау (килешү буенча сатып алу, урнаштыру, карап тоту, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);;

- Подгорная урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком җәю, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

-җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

- Өркеш авылы Подгорная урамында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Өркеш авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- карарны кабул ителгән итеп санарга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова